**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл җирлегенең Олы Мәрәтхуҗа авылында**
**гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

18 нче ноябрь 2020 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 нчы елның 18 нче ноябрендә булып узган гражданнар жыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлегенең Олы Мәрәтхуҗа торак пунктында турыдан-туры яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән,кондезге бүлектә укучы студентлардан кала, җирлек территориясендә тавыш бирү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме:

- Олы Мәрәтхуҗа авылы юлларына вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча түләү);
- Олы Мәрәтхуҗа авылы кышкы юлларын карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)”.

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 62 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 40 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 40 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлегенә керүче Олы Мәрәтхуҗа авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлегенең Олы Мәрәтхуҗа торак пунктында турыдан-туры яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән,кондезге бүлектә укучы студентлардан кала, җирлек территориясендә тавыш бирү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме:

- Олы Мәрәтхуҗа авылы юлларына вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча түләү);

- Олы Мәрәтхуҗа авылы кышкы юлларын карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ” соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. 2021 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге территориясе Олы Мәрәтхуҗа авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге бүлектә укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерергә:

- Олы Мәрәтхуҗа авылы юлларына вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча түләү);

- Олы Мәрәтхуҗа авылы кышкы юлларын карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

4. Граждannar җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126 йорт;

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Мәрәтхуҗа авылы, Ленин урамы, 71 йорт,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авыл җирлеге
башлыгы Р.М. Вафин